# МЕНӘ БЕЗ ДӘ ҮСЕП ҖИТТЕК, ӘНИ...

*ЛУИЗА ХӘЙРЕТДИНОВА музыкасы*
*РАВИЛ ФӘЙЗУЛЛИН сүзләре*

Без үстек.
Үсеп җиттек, әни
Менә без дә үсеп җиттек.

Кыр казлары
Түбәбездән үтә,
Элеккечә үтә,
Үтә икән...
Кыр казлары элеккечә
Түбәбездән үтә икән.
Күк һаман шул, шул,
Казлар гына бүтән икән.

Без үстек,
Үсеп җиттек, әни.
Менә без дә үсеп җиттек.

Сабан туйлар
Тау башында үтә.
Элеккечә үтә.
Үтә икән.
Сабан туйлар элеккечә
Тау башында үтә икән.
Тау һаман шул, шул,
Кызлар гына бүтән икән